РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 26 » 01 2024 ел №62

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы участок урманчылыгында, Бөгелмә урманчылыгында урнашкан линия объектлары территориясен чикләү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, 2023 елның 18 сентябрендәге «Башнефть» АНК ААҖнең «Карар бирү» турындагы 15-09-1124 санлы хаты, «Башнефть» АНК ААҖнең 2023 елның 17 ноябрендәге «Карар бирү» турындагы 15-09-1455 санлы хаты нигезендә, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир участоклары чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы участок урманчылыгында, Бөгелмә урманчылыгында урнашкан линия объектлары территориясен чикләү проектын әзерләүгә керешергә (алга таба – проект).
2. Проектның эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 43 маддәсенә ярашлы рәвештә билгеләргә.
3. Ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрүне исәпкә алып, проектны әзерләү вакытын 2024 елның маена кадәр билгеләргә.
4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ундүрт көн эчендә физик һәм юридик затларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына проектның тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина